**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАМСКО-УСТЬИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

ул. Карла Маркса, д.1А,
пгт. Камское Устье, 422820

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАМА ТАМАГЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Карл Маркс урамы, 1А йорт,
штп. Кама Тамагы, 422820

тел.: (884377) 2-00-20, e-mail: Kamuste.Ispolkom@tatar.ru, http://kamskoye-ustye.tatarstan.ru.

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 елның 29 мае № 288

«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районында автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында» нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 19 августындагы 544 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасында автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыруның аерым мәсьәләләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2026 елның 21 февралендәге 12-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 5 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 19 августындагы 544 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районында автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында» нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 статьяның 5 пунктында «даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның тиешле маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклык» сүзләрен «маршрутның тиешле төре реестрында язма» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам .

Җитәкче А.Ю.Сәлимов